**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

2018 елның 14 ноябре № 94

2014 елның 18 ноябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 113 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Салым кодексы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 36 маддәсе нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2014 елның 18 ноябрендәге “Физик затларның милкенә салым турында”гы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 113 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктының 1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әлеге пунктның 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан;

1.2. Карарның 2 пунктының 2 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“фатирлар, фатир өлешләре, бүлмә;”;

1.3. Карарның 2 пунктының 3 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак йортларны, торак йортларның бер өлешен;”.

1.4. түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт белән тулыландырырга:

“3.1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар, шулай ук күрсәтелгән гражданнарның балалары физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.”.

2. Әлеге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган срокта үз көченә керә.

2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә, 1 пунктчасының икенче абзацындагы, 2 пунктчасының икенче абзацындагы, 2 пунктның 3 пунктчасындагы икенче абзацындагы (әлеге Карар редакциясендә) нигезләмәләрнең гамәлдә булуы кагыла.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, Авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы Колхоз урамы, 16а йорты, китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы Рәисе** **В. П. Никитин**